КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 май

г.Казань

№ 649

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карары белән расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 июнь, 608 нче; 2022 ел, 21 октябрь, 1130 нчы; 2022 ел, 11 ноябрь, 1204 нче; 2023 ел, 20 март, 279 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның җиденче абзацында «агымдагы елның гыйнварыннан февраленә кадәр» сүзләрен «субсидия бирелгән елга кадәрге елның 1 ноябреннән 31 декабренә кадәр һәм (яки) агымдагы елның 1 гыйнварыннан 28 февраленә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта:

алтынчы абзацта татар текстында «агымдагы елның» сүзләре алдына «субсидия бирелгән елга кадәрге елның 1 ноябреннән 31 декабренә кадәр һәм (яки)» сүзләрен өстәргә;

уналтынчы абзацта татар текстында «агымдагы елның» сүзләре алдына «субсидия бирелгән елга кадәрге елның 1 ноябреннән 31 декабренә кадәр һәм (яки)» сүзләрен өстәргә;

15 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «агымдагы елның» сүзләре алдына «субсидия бирелгән елга кадәрге елның 1 ноябреннән 31 декабренә кадәр һәм (яки)» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта татар текстында «агымдагы елның» сүзләре алдына «субсидия бирелгән елга кадәрге елның 31 декабренә» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин